ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.07.2019 п.г.т. Алексеевское № 36

**“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә
оешмалар күрсәтә торган хезмәт шартларының
сыйфатын бәйсез бәяләү буенча Җәмәгать советы турындагы
Нигезләмәне раслау хакында” Алексеевск муниципаль районы
башлыгының 28.08.2018 ел, 85 нче карарына
үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясенең “Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре” дигән 9 октябрь, 1992 ел, 3612-1 нче Законның нигезләмәләренә туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 28.08.2018 ел, 85 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар күрсәтә торган хезмәт шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү буенча Җәмәгать Советы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.9 нчы пунктны түбәндәге роедакциядә бәян итәргә:

«3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Җәмәгать советы составына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы җирле хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре вәкилләре, шулай ук мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре; шулай ук “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында”гы 4 апрель, 2005 ел, 32-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган затлар керә алмый.

3.11 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Җәмәгать советы әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыралар.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Җәмәгать советы эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында

Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, шулай ук Алексеевск муниципаль районының Алексеевск район Советы бинасында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: ТР, Алексеевск районы, Алексеевск штб., Совет мәйданы, 1 нче йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**